РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 07 » декабрь 2018 ел Буа шәһәре № 382/ИК-п

Төзелешкә рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт тәкъдим итү
административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы 10 өлеше һәм 55 статьясы 4.1 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелешкә рөхсәт һәм кулланышка кертүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон формада юнәлдерү турында» 2017 елның 4 июлендәге 788 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелешкә рөхсәт һәм кулланышка кертүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон формада юнәлдерү турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 729 номерлы карары нигезендә, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТТЕ:**

1. ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 10 июлендәге 185/ИК-п номерлы карары белән расланган Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт тәкъдим итү административ регламентына (алга таба – регламент) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә::

1.1. 1.5 пункт:

4 абзацны түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«төзүче – анықы булган җир кишәрлегендә яки башка хокук иясенең (дәүләт (муниципаль) милектәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), “Росатом” Атом энергетикасы буенча дәүләт корпорациясе, “Роскосмос” Космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, дәүләтнең бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары яки җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән очракларда, килешү нигезендә үзләренең дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен аңа биргән) җир кишәрлегендә төзелеш, төзекләндерү, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын җимерү, шулай ук инженерлык тикшеренүләрен үткәрү, аларның төзелеше, төзекләндерелеше, капиталь ремонты

өчен проект документациясен әзерләүне тәэмин итүче физик яки юридик зат. Төзүче шәһәр төзелеше турындагы законнарда каралган үзенең функцияләрен техник заказчыга тапшырырга хокуклы;»;

5 абзацны түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«техник заказчы – төзүче тарафыннан вәкаләтләр бирелгән юридик зат һәм ул төзүче исеменнән инженерлык тикшеренүләрен үткәрү, проект документациясен әзерләү, төзелеш, төзекләндерү, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектын җимерү турында килешүләр төзи, бинаны күрсәтелгән эш төрләрен башкаруга әзерли, инженерлык тикшеренүләрен үткәрүче һәм (яки) проект документациясен әзерләү, төзелеш, төзекләндерү, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектын җимерүне башкаручы затларга, күрсәтелгән эшләрне башкарыр өчен кирәкле материаллар һәм документлар тәкъдим итә, проект документациясен раслый, капиталь төзелеш объектын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт алу өчен кирәкле документларны имзалый, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда каралган башка функцияләрне (алган таба шулай ук – техник заказчы функцияләре) гамәлгә ашыра.

Техник заказчы функцияләрен, Кодексның 47 статьясы 2_1 өлеше, 48 статьясы 4_1 өлеше, 52 статьясы 2_1 һәм 2_2 өлешләре, 55_31 статьясы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, инженерлык тикшеренүләре, архитектура-төзелеш проектлавы, төзелеш, төзекләндерү, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектын җимерү өлкәсендә үз-үзен көйләүче оешманың тиешле әгъзалары гына башкара ала;»;

1.2. 1.5 пункт:

6-12 абзацларны түбәндәге редакциядәге текстка алыштырырга:

Түбәндәге очракта төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителми:

1) эшмәкәрлек эшчәнлеген башкару белән бәйле булмаган максатлар өчен физик затка тәкъдим ителгән җир кишәрлегендә гараж төзү, төзекләндерү, яки бакчачылык җир кишәрлегендә торак йорт, бакча йорты, хуҗалык корылмалары төзү, төзекләндерү;

1_1) индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, төзекләндерү;

2) капиталь төзелеш объектлары булмаган объектларны төзү, төзекләндерү;

3) җир кишәрлегендә ярдәмче файдаланыштагы төзелешләр һәм корылмалар төзү;

4) капиталь төзелеш объектларын һәм (яки) аларның өлешләрен үзгәртү, әгәр андый үзгәрешләр конструктив һәм аларның ышанычлыгы һәм куркынычсызлыгы характеристикаларына кагылмаса һәм рөхсәт ителгән төзелеш, төзекләндерүнең шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән чик параметрларыннан артмаса;

4_1) капиталь төзелеш объектлары капиталь ремонты;

4_2) Россия Федерациясенең җир асты байлыклары турындагы законнары нигезендә әзерләнгән, килештерелгән һәм расланган файдалы казылмалар чыганакларын эшкәртү техник проекты яки җир асты байлыклары участокларын файдалану белән бәйле эшләрне башкаруга башка проект документацияләре белән каралган бораулау скважиналарын төзү, төзекләндерү;

4_3) Россия Федерациясенең чит илләрдә илчелекләрен, консуллыкларын һәм вәкиллекләрен төзү, төзекләндерү;

4_4) 0,6 мегапаскальга кадәр кертеп басым астындагы табигый газны транспортлау өчен билгеләнгән объектлар төзү, төзекләндерү;

5) башка очракларда, әгәр Кодекс, Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актлары, Татарстанның шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнары нигезендә төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәсә.»;

1.3. 2.4 пункт:

2 абзацны бетерергә.»;

1.4. регламентның 2.5 пункты:

1-19 абзацларны түбәндәге редакциядәге текстка алыштырырга:

Капиталь төзелеш объекты төзү, төзекләндерү очрагында:

1) җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче документлар, шул исәптән ачык сервитут билгеләү турындагы килешү, ачык сервитут билгеләү турындагы карар;

1_1) бюджет инвестицияләрен башкарган вакытта төзелгән җирле үзидарә органы тарафыннан муниципаль заказчы вәкаләтләрен, Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән очракларда, тапшыру турында килешү булганда, - күрсәтелгән килешү, әлеге килешү төзелгән хокук иясенең җир кишәрлегенә хокукларын билгеләүче документлар;

2) җир кишәрлегенең төзелешкә рөхсәт алуга гариза бирү көненә кадәр өч елдан да иртәрәк түгел бирелгән шәһәр төзелеше планы, яки линия объекты төзелешенә рөхсәт бирү очрагында территориянең планлаштыру проекты һәм территориянең межлау проекты реквизитлары (линия объектларын төзү, төзекләндерү өчен территорияне планлаштыру буенча документацияләр әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш), урнаштыру өчен җир кишәрлеге барлыкка китерү таләп ителмәгән линия объекты төзелешенә рөхсәт алу очрагында территориянең планлаштыру проекты реквизитлары;

3) проект документациясе эчтәлегендә булган материаллар:

а) аңлатма язуы;

б) җир кишәрлегенең, шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүматлар нигезендә, капиталь төзелеш объекты урнашачак урынны, аңа килүче юлларны һәм үтәли аралыкларны, ачык сервитут чикләрен, археологик мирас объектларын билгеләп башкарылган планлаштырылган оештыру схемасы;

в) җир кишәрлегенең, линия объектының линия объектларына кулланылган территорияләрне планлаштыру буена документлар составында расланган кызыл линияләр чигендә урнашуын раслаучы, планлаштырылган оештыру схемасы;

г) архитектура карарлары;

д) инженерлык җиһазлары турында мәгълүмат, проектланучы капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) урыннарын билгеләү белән инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләренең кушма планы;

е) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты;

ж) капиталь төзелеш объектын, аның өлешләрен җимерү буенча эшләрне оештыру проекты;

з) сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт объектларына һәм башка социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына, күрсәтелгән объектларны төзү, төзекләндерү очрагында, күрсәтелгән объектларның проект документациясенә экспертиза гамәлдәге Кодексның 49 статьясы нигезендә үткәрелмәгән шарт булганда, инвалидларның үтеп керүен тәэмин итү буенча чаралар исемлеге;

4) капиталь төзелеш объекты проект документациясе экспертизасының, әгәр андый проект документациясе Кодексның 49 статьясы нигезендә экспертизага бирелергә тиеш булса, уңай бәяләмәсе (Кодексның 48 статьясы 12_1 өлеше белән каралган очракта төзелешнең аерым этапларына кулланыла), Кодексның 49 статьясы 3_4 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, Кодексның 49 статьясы 6 өлешендә каралган очракларда проект документациясенең дәүләт экологик экспетизасы уңай бәяләмәсе;

5) рөхсәт ителгән төзелеш, төзекләндерү чик параметларыннан тайпылуга рөхсәт (әгәр төзүчегә андый рөхсәт Кодексның 40 статьясы нигезендә бирелгән очракта);

6) капиталь төзелеш объектының, мондый объектны төзекләндерү очрагында, гамәлдәге 6_2 пунктта күрсәтелгән күпфатирлы йортны төзекләндерү очракларыннан тыш, барлык хокук ияләре ризалыгы;

6_1) муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектында җирле үзидарә органы булган муниципаль заказчы төзекләндерү үткәргән очракта, аның хокук иясе муниципаль унитар предприятиесе, муниципаль бюджет яки автоном учреждениесе булганда, күрсәтелгән орган аңа карата тиешле рәвештә гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен яки милеккә милекче хокукын башкарса, – андый төзекләндерүне үткәрү турында, шул исәптән төзекләндерү барышында күрсәтелгән объектка китерелгән зыянны каплау шартларын һәм тәртипләрен билгеләүче килешү;

6_2) күпфатирлы йорт төзекләндерелгән очракта, торак законнары белән тәңгәл рәвештә кабул ителгән күпфатирлы йортта торак урыннары һәм машина кую урыннары милекчеләренең гомуми җыелышы карары, яки, әгәр андый төзекләндерү нәтиҗәсендә күпфатирлы йортның гомуми милке зурлыгы кечерәйсә, күпфатирлы йортта торак урыннар һәм машина кую урыннары милекчеләренең барысының да ризалыгы;

7) әгәр проект документациясенә дәүләтнеке булмаган экспертиза бәяләмәсе бирелгән очракта, проект документациясенә дәүләтнеке булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсен биргән юридик затның аккредитациясе турындагы таныклыкның күчерелмәсе;

8) әгәр мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр үткәргәндә андый объектның конструктив һәм ышанычлыгы һәм куркынычсызлыгының башка характеристикаларына кагыла икән, Россия Федерациясе законнарында мәдәни мирас объектлары турында каралган документлар;

9) капиталь төзелеш объекты төзү очрагында, аны урнаштыру уңаеннан, Россия Федерациясе законнарына тәңгәл рәвештә, территорияне аерым шартлар белән файдалану зонасын билгеләү таләп ителсә, яки капиталь төзелеш объектын төзекләндерү очрагында, аның нәтиҗәсендә төзекләндерелүче объектка карата территорияне аерым шартлар белән файдалану зонасы билгеләү таләп ителсә яки моңа кадәр билгеләнгән территорияне аерым шартлар белән файдалану зонасын үзгәртү таләп ителсә, территорияне аерым шартлар белән файдалану зонасын билгеләү яки үзгәртү турында карарның күчерелмәсе.»;

20-24 абзацларны бетерергә;»;

25-27 абзацларны бетерергә;»;

1.5. регламентның 2.6 пункты:

1-7 абзацларны алыштырырга:

«2.5 пунктының 1-8 пунктларында күрсәтелгән документлар (аларның күчерелмәләре яки аларның эчтәлегендә булган мәгълүматлар), әгәр төзүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль рәвештә тәкъдим итмәгән булса, әлеге документлар буенча эш алып барган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалардан, төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза алу көненнән өч эш көненнән дә соңармыйча, Башкарма комитет тарафыннан соратып алына.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән органнарның ведомствоара соратулары буенча документлар (аларның күчерелмәләре яки аларның эчтәлегендә булган мәгълүматлар), әлеге документлар буенча эш алып барган җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар тарафыннан тиешле ведомствоара сорату кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә соңармаган срокта тәкъдим ителә.

8-10 абзацларны бетерергә;

1.6. 2.9 пункт:

2-6 абзацларны түбәндәге редакциядәге текстка алыштырырга:

Регламентның 2.5 пунктында каралган документлар булмаса, яки тәкъдим ителгән документлар төзелешкә рөхсәт алу өчен тәкъдим ителгән җир кишәрлеге шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзү, төзекләндерү таләпләренә, яки линия объектын төзүгә рөхсәт бирү очрагында территориянең планлаштыру проекты һәм территорияне межлау проекты таләпләренә (линия объектын төзү, төзекләндерү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш), шулай ук җир кишәрлеген рөхсәт белән файдалану һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм башка законнарына тәңгәл рәвештә билгеләнгән һәм төзелешкә рөхсәт бирелгән датага гамәлдә булган рөхсәт ителгән төзелеш, төзекләндерүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә тәңгәл килмәсә, Башкарма комитет төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарта. Әлеге статьяның 7_1 өлешенә тәңгәл рәвештә соратылган документларны алмау яки вакытында алмау төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тартуга нигез булып тора алмый.

Әлеге статьяның 11_1 өлешендә каралган очракларда, төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен шулай ук Россия Федерациясе субъектының мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле органыннан капиталь төзелеш объектының проект документациясе бүлеге тарихи җирлекне саклау предметына һәм капиталь төзелеш объектының, федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек чикләрендә урнашкан территориаль зоналарга кулланылучы шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән, архитектур карарларның таләпләренә тәңгәл килмәве турында бәяләмә килүе дә нигез булып тора.

7-8 абзацларны бетерергә.;

9-12 абзацларны түбәндәге редакциядәге текстка алыштырырга:

«Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тартуга түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) җир кишәрлегенә хокуклар күчү, җир асты байлыкларын файдалану хокукы, җир кишәрлеге оештыру турындагы белдерүдә, Кодексның 51 статьясы 21_10 өлеше 1-4 пунктларына тәңгәл рәвештә каралган документларның реквизитлары булмау, яки Кодексның 51 статьясы 21_13 өлешендә күрсәтелгән очракларда, җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче документлар булмау, яки төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза кергән очракта, төзелешкә

рөхсәткә, бары тик андый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайту сәбәпле үзгәрешләр кертү турындагы гаризадан тыш, Кодексның 51 статьясы 7 өлешендә каралган документлар булмау;

2) җир кишәрлегенә хокуклар күчү, җир асты байлыкларын файдалану хокукы, җир кишәрлеге оештыру турындагы белдерүдә мәгълүматларның дөрес булмавы;

3) капиталь төзелеш объектын урнаштыру планы, Кодексның 51 статьясы 21_7 өлешендә каралган очракларда, оештырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән, капиталь төзелеш объектларын төзү, төзекләндерү таләпләренә тәңгәл килмәве. Шул ук вакытта җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы, Кодексның 51 статьясы 21_10 өлешендә күрсәтелгән белдерүне юнәлдергәннән соң өч көннән дә иртәрәк бирелергә тиеш түгел;

4) капиталь төзелеш объектын урнаштыру планының, төзелешкә рөхсәт алу өчен яки төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кетү турында гариза кергән очракта, бары тик андый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайту сәбәпле үзгәрешләр кертү турындагы гаризадан тыш, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү өчен тәкъдим ителгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән, капиталь төзелеш объекты төзү, төзекләндерү таләпләренә тәңгәл килмәве. Төзелешкә рөхсәт алганнан соң бирелгән җир кишәрлеге шәһәр төзелеше планы төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү өчен тәкъдим ителгән очракта, андый шәһәр төзелеше планы төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза юнәлдерелгән көнгә кадәр өч елдан да иртәрәк бирелмәгән булырга тиеш;

5) планлаштырылган капиталь төзелеш объектының җир кишәрлеген рөхсәтле файдалануга һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм Кодексның 51 статьясы 21_7 өлешендә каралган очракларда, яки төзелешкә рөхсәткә, бары тик андый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайту белән бәйле үзгәрешләр кертү турындагы гаризадан тыш, төзүчедән төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза килгән очракта, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы карар кабул ителгән датага гамәлдә булган чикләүләргә тәңгәл килмәве;

6) төзелешкә рөхсәткә, бары тик андый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайту белән бәйле үзгәрешләр кертү турындагы гаризадан тыш, төзүче тарафыннан төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза килгәндә, капиталь төзелеш объектын урнаштыру планының рөхсәт ителгән төзелеш, төзекләндерүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә тәңгәл килмәве;

7) Башкарма комитет карамагында муниципаль җир контролендә төзелешкә рөхсәткә, андый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайту уңаеннан үзгәрешләр кертү турында гариза бирелгән көнгә төзелеш, төзекләндерү буенча эшләр башланмау факты ачыклану турында мәгълүмат булуы яки дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының әлеге эшләрнең башлануы турында белдерү булмавы турындагы мәгълүматы, әгәр андый белдерүне җибәрү Кодексның 52 статьясы 5 өлеше таләпләре нигезендә мәҗбүри булып торган очракта;

8) төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризаны төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамлануга ун эш көненнән дә соңармыйча бирү.»;

1.7. регламентның 3.3 пункты:

түбәндәге редакциядәге абзац белән тулыландырырга:

«төзелешкә рөхсәт һәм объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү өчен, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы 7 өлеше һәм 55

статьясы 3 һәм 4 өлешләрендә күрсәтелгән, электрон формада юнәлдерелүче документларны кабул иткәндә, «Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте» дәүләт мәгълүмати системасын файдаланырга.».

1.8. регламентның 3.4.1 пункты:

«3.4.1. 2.5 пунктының 1-8 пунктларында күрсәтелгән документлар (аларның күчерелмәләре яки аларның эчтәлегендә булган мәгълүматлар), әгәр төзүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль рәвештә тәкъдим итмәгән булса, әлеге документлар буенча эш алып барган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалардан, төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза алу көненнән өч эш көненнән дә соңармыйча, Башкарма комитет тарафыннан соратып алына.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән органнарның ведомствоара соратулары буенча документлар (аларның күчерелмәләре яки аларның эчтәлегендә булган мәгълүматлар), әлеге документлар буенча эш алып барган җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар тарафыннан тиешле ведомствоара сорату кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә соңармаган срокта тәкъдим ителә.»;

1.9. 3.7 бүлеген тексттан алып ташларга.»;

1.10. 3.8, 3.9, 3.10, 3.11 номерлы бүлекләрне 3.7, 3.8, 3.9, 3.10 номерлар дип исәпләргә.»;

1.11. 5.1 пункт:

1 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә, электрон формада Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне гамәлгә куйган (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы) ачык-хокукый төзелештәге тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органы), шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга бирелә. Башкарма комитет җитәкчесе карарына һәм кылган гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять югарырак торган органга (андый булганда) бирелә яки андый булмаган очракта турыдан-туры Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарына һәм кылган гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәк карарына һәм кылган гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга яки Татарстан Республикасы норматив хокукый акты белән вәкаләтләнгән вазифаи затка бирелә. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарына һәм кылган гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять әлеге оешмаларның җитәкчесенә бирелә.»;

1.12. 5.1 пунктының 1 пунктчасы:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) дәүләт яки муниципаль хезмәт тәкъдим итү турында соратуны, әлеге Федераль законның 15_1 статьясында күрсәтелгән соратуны теркәү срогын бозу;»;

1.13. 5.1 пунктының 2 пунктчасы:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль хезмәт тәкъдим итү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләр кылуына (гамәлләр кылмавы) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять,

әгәр карарларына һәм гамәлләр кылуына (гамәлләр кылмавы) шикаять бирелгән күпфункцияле үзәккә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр тәкъдим итү буенча функция йөкләнгән очракта бирелергә мөмкин;»;

1.14. 5.1 пунктының 5 пунктчасы:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) әгәр баш тартуга нигез федераль законнар һәм аларга тәңгәл рәвештә Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса, муниципаль хезмәт тәкъдим итүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләр кылуына (гамәлләр кылмавы) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять, әгәр карарларына һәм гамәлләр кылуына (гамәлләр кылмавы) шикаять бирелгән күпфункцияле үзәккә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр тәкъдим итү буенча функция йөкләнгән очракта бирелергә мөмкин;»;

1.15. 5.1 пунктының 7 пунктчасы:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Башкарма комитет, Башкарма комитетның вазифаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_1 өлешендә каралган оешмалар, яки аларның хезмәткәрләре муниципаль хезмәт тәкъдим итү нәтиҗәсендә бирелгән документларда алар ясаган хәреф-хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләргә билгеләнгән срокны бозуы. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләр кылуына (гамәлләр кылмавы) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять, әгәр карарларына һәм гамәлләр кылуына (гамәлләр кылмавы) шикаять бирелгән күпфункцияле үзәккә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр тәкъдим итү буенча функция йөкләнгән очракта бирелергә мөмкин;»;

1.16. 5.1. пунктының 9 пунктчасы:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне, әгәр аларны тәкъдим итүне туктатуга нигез федераль законнарда һәм аларга тәңгәл рәвештә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса, туктату. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләр кылуына (гамәлләр кылмавы) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять, әгәр карарларына һәм гамәлләр кылуына (гамәлләр кылмавы) шикаять бирелгән күпфункцияле үзәккә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр тәкъдим итү буенча функция йөкләнгән очракта бирелергә мөмкин».»;

1.17. 5.2 пункт:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Башкарма комитет, Башкарма комитетның вазифаи заты, муниципаль хезмәткәр, Башкарма комитет җитәкчесенең карарларына һәм кылган гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен, Башкарма комитетның рәсми сайтын, Татарстан Республикасы Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталын (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып юнәлдерелә ала, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителә ала. Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм кылган гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) шикаять почта аша, Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен, Башкарма комитетның рәсми сайтын, Татарстан Республикасы Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталын (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып юнәлдерелә ала, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителә ала. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_1 өлешендә каралган оешмалар, шулай ук аларның хезмәткәрләре карарларына һәм кылган гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) шикаять почта аша, Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен, Башкарма комитетның рәсми сайтын, Татарстан Республикасы Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталын (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып юнәлдерелә ала, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителә ала.»;

1.18. 5.3 пункт:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5.3. Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга, яисә югарырак торган органга (андый булганда) килгән шикаятьләр аны теркәгән көннән унбиш эш көне дәвамында каралырга тиеш, ә Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә ясаган хәреф-хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына яки андый төзәтүләргә билгеләнгән срокның бозылуына шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән биш эш көне дәвамында.

1.19. 5.4 пункт:

1 пунктчаны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) муниципаль хезмәт тәкъдим итүче органның, муниципаль хезмәт тәкъдим итүче органның вазифаи заты, яисә муниципаль хезмәткәр, күпфункцияле үзәк, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәре, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның исемнәре;»;

1.20. 5.4 пункт:

3 пунктчаны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Башкарма комитет, муниципаль хезмәт тәкъдим итүче органның вазифаи заты, яисә муниципаль хезмәткәр, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_1 өлешендә каралган оешмалар һәм аларның

хезмәткәрләренең шикаять бирелгән карарлары һәм гамәлләр кылуы (гамәлләр кылмавына) турында мәгълүматлар;»;

1.21. 5.4 пункт:

4 пунктчаны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) дәүләт хезмәте тәкъдим итүче органның, муниципаль хезмәт тәкъдим итүче органның, дәүләт хезмәте тәкъдим итүче органның яки муниципаль хезмәт тәкъдим итүче органның вазифаи заты, яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәткәр, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1_1 өлешендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләре карарлары һәм кылган гамәлләре (гамәлләр кылмавы) белән килешмәгән гариза бирүче нигезләнгән дәлилләр. Гариза бирү тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (алар булганда), яисә аларның күчерелмәләре тәкъдим ителә ала.»;

1.22. 1нче кушымтада Гариза документлары исемлеге:

Гаризага сканерланган түбәндәге документлар куела:

1) җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче документлар, шул исәптән ачык сервитут билгеләү турындагы килешү, ачык сервитут билгеләү турындагы карар;

1_1) бюджет инвестицияләрен башкарганда, Россия Федерациясенең бюджет законнары белән билгеләнгән очракларда, җирле үзидарә органы тарафыннан муниципаль заказчы вәкаләтләрен тапшыру турындагы килешү булганда, - күрсәтелгән килешү, әлеге килешү төзелгән хокук иясенең җир кишәрлегенә хокукын билгеләүче документлар;

2) җир кишәрлегенең төзелешкә рөхсәт алуга гариза бирү көненә кадәр өч елдан да иртәрәк түгел бирелгән шәһәр төзелеше планы, яки линия объекты төзелешенә рөхсәт бирү очрагында территориянең планлаштыру проекты һәм территориянең межлау проекты реквизитлары (линия объектларын төзү, төзекләндерү өчен территорияне планлаштыру буенча документацияләр әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш), урнаштыру өчен җир кишәрлеге барлыкка китерү таләп ителмәгән линия объекты төзелешенә рөхсәт алу очрагында территориянең планлаштыру проекты реквизитлары;

3) проект документациясе эчтәлегендә булган материаллар:

а) аңлатма язуы;

б) җир кишәрлегенең, шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүматлар нигезендә, капиталь төзелеш объекты урнашачак урынны, аңа килүче юлларны һәм үтәли аралыкларны, ачык сервитут чикләрен, археологик мирас объектларын билгеләп башкарылган планлаштырылган оештыру схемасы;

в) җир кишәрлегенең, линия объектының линия объектларына кулланылган территорияләрне планлаштыру буена документлар составында расланган кызыл линияләр чигендә урнашуын раслаучы, планлаштырылган оештыру схемасы;

г) архитектура карарлары;

д) инженерлык җиһазлары турында мәгълүмат, проектланучы капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) урыннарын билгеләү белән инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләренең кушма планы;

е) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты;

ж) капиталь төзелеш объектын, аның өлешләрен җимерү буенча эшләрне оештыру проекты;

3) сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт объектларына һәм башка социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына, күрсәтелгән объектларны төзү, төзекләндерү очрагында, күрсәтелгән объектларның проект документациясенә экспертиза гамәлдәге Кодексның 49 статьясы нигезендә үткәрелмәгән шарт булганда, инвалидларның үтеп керүен тәэмин итү буенча чаралар исемлеге;

4) капиталь төзелеш объекты проект документациясе экспертизасының, әгәр андый проект документациясе Кодексның 49 статьясы нигезендә экспертизага бирелергә тиеш булса, уңай бәяләмәсе (Кодексның 48 статьясы 12_1 өлеше белән каралган очракта төзелешнең аерым этапларына кулланыла), Кодексның 49 статьясы 3_4 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, Кодексның 49 статьясы 6 өлешендә каралган очракларда проект документациясенең дәүләт экологик экспетизасы уңай бәяләмәсе;

5) рөхсәт ителгән төзелеш, төзекләндерү чик параметларыннан тайпылуга рөхсәт (әгәр төзүчегә андый рөхсәт Кодексның 40 статьясы нигезендә бирелгән очракта);

6) капиталь төзелеш объектының, мондый объектны төзекләндерү очрагында, гамәлдәге 6_2 пунктта күрсәтелгән күпфатирлы йортны төзекләндерү очракларыннан тыш, барлык хокук ияләре ризалыгы;

6_1) муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектында җирле үзидарә органы булган муниципаль заказчы төзекләндерү үткәргән очракта, аның хокук иясе муниципаль унитар предприятиесе, муниципаль бюджет яки автоном учреждениесе булганда, күрсәтелгән орган аңа карата тиешле рәвештә гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен яки милеккә милекче хокукын башкарса, – андый төзекләндерүне үткәрү турында, шул исәптән төзекләндерү барышында күрсәтелгән объектка китерелгән зыянны каплау шартларын һәм тәртипләрен билгеләүче килешү;

6_2) күпфатирлы йорт төзекләндерелгән очракта, торак законнары белән тәңгәл рәвештә кабул ителгән күпфатирлы йортта торак урыннары һәм машина кую урыннары милекчеләренең гомуми җыелышы карары, яки, әгәр андый төзекләндерү нәтиҗәсендә күпфатирлы йортның гомуми милке зурлыгы кечерәйсә, күпфатирлы йортта торак урыннар һәм машина кую урыннары милекчеләренең барысының да ризалыгы;

7) әгәр проект документациясенә дәүләтнеке булмаган экспертиза бәяләмәсе бирелгән очракта, проект документациясенә дәүләтнеке булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсен биргән юридик затның аккредитациясе турындагы таныклыкның күчерелмәсе;

8) әгәр мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр үткәргәндә андый объектның конструктив һәм ышанычлыгы һәм куркынычсызлыгының башка характеристикаларына кагыла икән, Россия Федерациясе законнарында мәдәни мирас объектлары турында каралган документлар;

9) капиталь төзелеш объекты төзү очрагында, аны урнаштыру уңаеннан, Россия Федерациясе законнарына тәңгәл рәвештә, территорияне аерым шартлар белән файдалану зонасын билгеләү таләп ителсә, яки капиталь төзелеш объектын төзекләндерү очрагында, аның нәтиҗәсендә төзекләндерелүче объектка карата территорияне аерым шартлар белән файдалану зонасы билгеләү таләп ителсә яки

моңа кадәр билгеләнгән территорияне аерым шартлар белән файдалану зонасын үзгәртү таләп ителсә, территорияне аерым шартлар белән файдалану зонасын билгеләү яки үзгәртү турында карарның күчерелмәсе;

Әлеге исемлекнең 1-5, 7 һәм 9 пунктларында күрсәтелгән документлар (аларның күчерелмәләре яки аларның эчтәлегендә булган мәгълүматлар), әгәр төзүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль рәвештә тәкъдим итмәгән булса, әлеге документлар буенча эш алып барган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалардан, төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза алу көненнән өч эш көненнән дә соңармыйча, Кодексның 51 статьясы 7 өлеше беренче абзацында күрсәтелгән органнар тарафыннан соратып алына.

Кодексның 51 статьясы 7 өлеше беренче абзацында күрсәтелгән органнарның ведомствоара соратулары буенча документлар (аларның күчерелмәләре яки аларның эчтәлегендә булган мәгълүматлар), әлеге документлар буенча эш алып барган җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар тарафыннан тиешле ведомствоара сорату кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә соңармаган срокта тәкъдим ителә.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгару көненнән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе Р.Р. Кәмәртдинов